

Мордовиядә XXVI Ботенроссия сыер савучылар конкурсы Старошайгово районынын ООО «Агрофирма «Новотроицкая» базасында узды. Быелгы конкурста Россиянен 60 тобәгеннән 66 сыер савучы катнашты.
Чаранын максаты - алдынгы эш тәжрибәсен популярлаштыру, сотле мал-туар производствосында прогрессив технологияләр булдыру, сот табышында нәтижәләрне кvтәрv һәм сыерларны машина белән саву процессында операторларнын профессиональ осталыкларын кvрсәтv.

Конкурсантлар биш номинация буенча коч сынашкан. Абсолют чемпион исеменә Мордовиянен бәйге узган хужалык сыер савучысы Людмила Семёнкина лаек булды. Ул максималь кvләмдә баллар иясе – 99,97. Конкурста жинvче топ приз – «Лада Гранта» маркалы автомобиль, диплом һәм кыйммәтле бvләкләр белән бvләкләнде.
Людмила Викторовнанын Мордовия данын яклап конкурста катнашуы беренче тапкыр гына тvгел икән инде. Мона кадәр дә ярышларда vзен сынап караган. Бу конкурста Людмила ханымга бәхет елмая. Доресрәге, конкурсларда катнашып тәмам остарып житә, ничек эшләргә, жавап бирәсен ойрәнә. Бәйге дигәч тә, анда зур тогәллек кирәк. Саву аппаратын билгеләнгән вакытка сvтеп жыярга, сыерларнын холкын белеп тиешенчә саварга, сорауларга дорес итеп жавабын да бирергә. Ә андагы сораулар бер дә жинел тvгел. Ул: «Таләпләр буенча сыер савучылар саву жиһазын сvтеп жыю эшен 5 минут 30 секунд эчендә башкарырга тиеш иде. Монда практик яктан да, теоретик яктан да белемле булу кирәк. Сорауларга тогәл жавап бирvдән, эшләп кvрсәтvдән тыш, санитар таләпләр дә зурдан».
Әйтеп китәргә кирәктер, Татарстаннан Сания Насыйбуллина исә «Хатын-кыз. 45 яшьтән олкән ветераннар» номинациясендә лаеклы икенче урынны яулый.

**Наилә Насырова**